КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 8 май г.Казань № 678

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусынраслый торган таныклык бирү тәртибе турында» 2024 ел, 17 октябрь, 893 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклык бирү тәртибе турында» 2024 ел, 17 октябрь, 893 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 20 ноябрь, 971 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклык бирү тәртибендә:

5 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

гаризаны теркәгән көннән соң өч эш көне эчендә Идарәгә (бүлеккә) гаризага кушымта итеп бирелгән документларның төп нөсхәләрен яисә нотариаль таныкланган күчермәләрен тапшыру белән «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып (алга таба - Бердәм портал), шулай ук «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып (алга таба - Төбәк порталы) электрон рәвештә;

таныклык бирү турында кабул ителү хакында хәбәрнамә алган көннән соң өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүченең һәм аның хатынының (иренең) 3 x 4 см зурлыгындагы фотосурәтләрен Идарәгә (бүлеккә) тапшыру белән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша;»;

6 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала (балалар) туу турында таныклык күчермәләре, баланың Россия Федерациясе гражданлыгы булуын

раслый торган тамга куелган һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе;»;

тугызынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданинының шәхесен раслаучы документ турында.»;

9 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау һәм (яисә) аларның рәвеше һәм эчтәлеге буенча әлеге Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;»;

әлеге карар белән расланган Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклыкның бердәй үрнәген раслауга бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы үз көченә кергән көнгә гамәлдә булган, Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклыкны яңадан рәсмиләштерү тәртибендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча таныклыкны яңадан рәсмиләштерү турында гариза (алга таба – гариза) Татарстан Республикасы территориясендә күпбалалы гаилә әгъзаларының берсе яшәү (булу) урыны буенча Идарәгә (бүлеккә) гариза бирүче яки ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән зат тарафыннан бирелә:

таныклыкны яңадан рәсмиләштерү турында кабул ителү хакында хәбәрнамә алган көннән соң өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүченең һәм аның хатынының (иренең) 3 x 4 см зурлыгындагы фотосурәтләрен Идарәгә (бүлеккә) тапшыру белән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша;

почта аша җибәреп;

шәхсән.

Гариза бирүченең тормыш хәле нинди булуга карап, гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала (балалар) туу турында таныклык күчермәләре, баланың Россия Федерациясе гражданлыгы булуын раслый торган тамга куелган һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән никахлашуны теркәү турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең күчермәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең күчермәсе;

закон көченә кергән баланың (балаларның) яшәү урынын билгеләү турында суд карары яки ата белән ана аерым яшәгәндә ата-ана арасында баланың (балаларның) яшәү урынын билгеләү турында килешү күчермәсе;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада белем бирүнең көндезге рәвеше буенча 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланы (балаларны) укыту факты турында (Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү

оешмасында укудан тыш) бирү датасы гариза бирү датасыннан 60 календарь көннән артмаган белешмәнең күчермәсе;

баланы (балаларны) уллыкка алу турында суд карары күчермәсе;

Россия Федерациясеннән читтә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку формасы буенча уку турында чит ил дәүләте территориясендә бирелгән документ һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсенең күчермәсе;

гариза бирүченең һәм аның хатынының (иренең) 3 х 4 см зурлыгында фотосурәтләре;

Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклык (булганда).

Мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче шәхесне раслаучы документ күрсәтә.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган булса, төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана. Документларның күчермәләре бер нөсхәдә бирелә.

Гариза Идарәгә (бүлеккә) почта аша җибәрелергә мөмкин. Бу очракта гаризага документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләре теркәлә.

Гариза бирүче Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган документларның дөреслеге өчен җавап бирә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин